| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.02.2022 Казан ш. № 386-р

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән, Нурлат, Саба муниципаль районнары территорияләре газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, "Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында" 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ хатын истә тотып (21.01.2021 № 82/04), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәре объектларының («Газ бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:20:093501:2045; 16:49:010205:822; 16:49:011906:2600)») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 21680 +/- 71 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәре объектларының («Газ бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:56:000000:491; 16:56:000000:517; 16:56:000000:520; 16:56:000000:522; 16:56:000000:525)») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның

текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 7958 +/- 18 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәре объектларының («Газ бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:35:000000:972; 16:35:000000:1070; 16:35:000000:1167; 16:35:000000:1168; 16:35:090201:174; 16:35:090504:105)») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 75994 +/- 55 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В. Захаровка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**